**Тынгысыз җаннар мәңге яшь калалар...**

Рәмзия Мөхетдинова (Гыймазетдинова) 1946 елның 23 ноябрендә колхозчы гаиләсендә туып үсә. Әтисе Гәрәй ага Бөек Ватан сугышыннан аягы яраланып кайта. Колхоз, сельпо рәисе булып эшли. Әмма яраларыннан терелеп бетә алмыйча, 1951 елны вафат була. Әни кеше – Мәрьям апа колхозда эшли, 3 бала үстерә.

Мәктәптә укыган елларда ук бик актив, чая, кыю, оештыру сәләтенә ия булган Рәмзиянең уңай сыйфатларын укытучылар хуплыйлар, аңа төрле поручениеләр йөклиләр. 10-11 нче сыйныфларда укыганда ук 3 инвалид баланы өйдә укыту эшен ышанып аңа тапшыралар.

Мәктәпне тәмамлаганнан соң, Алабуга педагогия институтына укырга керә. Биредә дә студент кыз Рәмзия тырышып укый, җәмәгать эшләрендә актив катнаша: татар телендә үткән һәр концерт, спектакль һәм кичәләрне оештыруда башлап йөри, үзе алып баручы да була. Мәктәптә тиктормас кызны "Кычыткан чыпчыгы" дип, атаган булсалар, институтта үзен "Ут-кыз" дип йөртәләр.

Яшь белгеч беренче һөнәр адымнарын Алабуга районы Иске Юраш мәктәбендә укытучы һәм тәрбия эшләре буенча директор урынбасары булып эшли башлый. Булачак тормыш иптәше Рафис белән дә шунда таныша.

1973 елны туган авылына кайтып, Рәмзия мәктәптә рус теле һәм әдәбияты укыта. Өлкән вожатый Әдия апа Ибраева пенсиягә киткәч, 1980 нче елдан өлкән пионер вожатый вазыйфасын да үз өстенә ала. Ә ул вазыйфаның очы да, кырые да юк икән ич. Яшь вожатый шуны аңлый: туган ягын, мәктәбен, гаиләсен горурландырырлык чын патриотлар үстерүгә көчен дә, белемен дә, вакытын да кызганмаячак ул. Һәм бу чыннан да шулай була.

1994 елны, авылдашыбыз Марсель Гыймазетдиновның вафатына 1 ел тулу уңаеннан, үзе җитәкләгән сыйныф укучылары белән шагыйрьнең биографиясенә һәм иҗатына багышланган музей-бүлмә ачуга ирешә ул. Казан комиссиясе музейга "Мәктәпнең әдәби музее" дигән статус бирә. Шул көннән башлап, музейда йөзләгән кешеләр булып (алар арасында драматург Туфан Миңнуллин, җырчы Вафира Гыйззәтуллина, язучы Нәбирә Гыйматдинова кебек шәхесләр дә бар) төрле чараларны тамаша кылалар.

Вожатый Рәмзия пионер оешмасында һәрдаим оештырылган бәйге-конкурсларга, төрле экспедиция-операцияләргә пионерларны күпләп җәлеп итте, аларда зур кызыксыну уятты, бу ярышларда һичшиксез җиңеп чыгачакларына ышаныч тудырды. Төрле эзләнү-өйрәнү чаралары аша балаларда туган ягыбыз, аның тарихы, кешеләре турында зур мәгълүмат тупларга, балалар күңелендә үз төбәгебез белән горурлану, аны ярату хисләре тәрбияләүгә зур көч куйды, армый-талмый Балачакка хезмәт итте.

Укытучы һәм вожатый булып эшләгән елларда, мөгаллимәнең үзенә дә нинди генә конкурс-бәйгеләрдә катнашырга туры килми. Ул аларның һәрберсенә теләп һәм җентекләп әзерләнә.1995 нче елда, иң яхшы укытучы исемен яулау өчен үткәрелгән бәйгедә катнашып, ул "Ел укытучысы" дигән мактаулы исемгә лаек була. Эшләгән дәвердә: "Вожатый-инструктор", "Өлкән

вожатый-методист”,”Өлкән укытучы”, “Укытучы-методист”, “Балаларга тугрылык өчен” дигән Александр Денежкин исемендәге премия лауреаты, “I категорияле укытучы”, “РФ нең гомуми белем бирү өлкәсендә шәрәфле (почетлы) хезмәткәре” дигән һ.б. мактаулы исемнәрне лаеклы рәвештә алуга ирешә ул.

Ә сәхнәдә Рәмзия ханымны кем генә итеп күрмисең? Ул концерт алып баручы да, сценарий-композицияләрне үзе язучы да, спектакльләрдә режиссер да, төп рольне башкаручы да. Сәхнәгә мәхәббәтне ул иренә, улы һәм ике кызына да күчерә алды. Алар “Гаилә ансамбльләре” конкурсларында, авылда һәм районда үткәрелгән бик күп мәдәни чараларда катнашучылар да булдылар. Рәмзия ханым үзенә һәрчак булышкан иренә һәм балаларына чиксез рәхмәтле.

Рәмзия Гәрәй кызы Мөхетдинованың тагын бер күркәм сыйфатын әйтеп китмичә булмый. Ул гади һәм танылган авылдашлары турында газеталарда еш яза, алар турында башкаларга да сөйләргә, күбрәк белдерергә тырыша. Үзе турында уйламый ул, ә мактаулы якташларын тагын да данлыйсы, күрсәтәсе килә аның. Бу игелекле ханымның менә шундый теләк-омтылышларының нәтиҗәсе булып, инде 3 китабы дөнья күрде. Туган мәктәбенә багышланган “Укытучым-кадерлем”, районташыбыз, мәшһүр җырчы Вафирә Гыйззәтуллинаның 70 еллыгына – “Бөркет йөрәкле былбыл” һәм танылган табиб, профессор Рифкать Таҗиев турында “Гомер мизгелләре бүләк итәм...” дигән китаплар алар.

Холкы-фигыле белән ачык, тиз аралашучан, тынгысыз, эзләнүчән, туры сүзле, гаделлек-дөреслекне яклаучы җан ул – Рәмзия ханым Мөхетдинова. Аның ирешкән уңышлары, тәрбия тәҗрибәсе, яшьләргә, авылдашларга өләшкән үгет-нәсыйхәтләре – болар бернинди бизмәнгә дә салып үлчәнми торган олы байлык.

Лаеклы ялга чыкканнан соң да, Рәмзия Гәрәй кызы һәи ире Рафис,авыл кешеләре буларак, авылча тормыш алып баралар: мал-туар асрыйлар, үзләренә һәм балаларына җитәрлек кенә бәрәңге, җиләк-җимеш үстерәләр. Шәһәрдән 4 оныгы кайткач, Рәмзия әби көннәр буе оныклары белән мәш килә. Ул 5 вакыт намазын калдырмый, мәчет оештырган чараларда катнаша, китапханәгә йөри, мәдәният йортында тематик кичәләр оештыра. Җыеп кына әйткәндә, Ходай биргән гомереннән, тормышыннан канәгать булып яши ул.


15 яшьлек Рәмзия






Рәмзия һәм Рәйсә Гимазетдиновалар









Рәмзия Мөхетдинова Менделеев үзәк китапханәсендә чыгыш ясый



Артур, Валерий, Айгөл, Рәмзия апа, Айназ